Г.Г. Әхмәдгалиева, Р.С. Сахбетдинова
КФУның Алабуга институты

# Н.ГЫЙМАТДИНОВА ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ПЕЙЗАЖ ТУДЫРУЧЫ СУРӘТЛӘҮ ЧАРАЛАРЫ

Тел – кешелекнең иң зур хәзинәсе. Ул – искиткеч могҗизалар тудыра ала торган, зур тәэсир итү көченә ия булган серле хәзинә. Аның төп коралы – сүз. Сүз, телнең күрке буларак, тылсымлы көчкә ия. Аны күңел көзгесенә тиңлиләр, чөнки йөрәктән чыккан сүз генә йөрәккә барып җитә. Ул кешенең дөньяны танып-белү тәҗрибәсен башкаларга җиткерә, аралашуның төп чарасы да булып тора. Татар халкы бик борынгы заманнардан ук үзенең барлык хис-кичерешләрен, теләк-омтылышларын матур әдәбиятның чишмә башы булган моңлы җыр, тылсымлы әкият, үткен мәкаль, илаһи бәет, серле риваятьләр аша чагылдырган. Матур әдәбият исә җәмгыять тормышының күп өлкәләрен үз эченә ала. Ул тел чараларын сайларга, әдәби тел нормаларын билгеләргә, аны эшкәртергә, ныгытырга, үстерергә ярдәм итә. Сүз сәнгате зур көчкә ия, чөнки сүзләр кешегә һава белән су, икмәк белән тоз, кояш белән мәхәббәт кебек кирәк. Сүздән башка тел дә, халык та яши алмый. Сәнгать әсәренә матурлык, камиллек хас. Кеше хисенә ул үзенең гүзәллеге, төзеклеге белән йогынты ясый. Матур әдәбият әсәрләрендә тел-сурәтләү чараларын күпләп куллану әсәрнең кыйммәтен, укучының хисенә тәэсир итү көчен арттыра.

Филология фәннәре докторы Х.Курбатов та аның эшчәнлеген югары бәяли: “Нәбирә Гыйматдинова повестьлары идея-эчтәлек ягыннан да, төзелеш-композицион үзенчәлекләрен карасаң да – чып-чынлап поэзия. Бу автор – хәзерге татар әдәбиятында поэтик прозаның зур остасы, чөнки әсәрдәге вакыйгалар, андагы персонаж һәм табигать күренешләре – һәммәсе укучының күз алдыннан китмәслек дәрәҗәдә сәнгатьле итеп тасвирлана. Әсәрләрнең кайсын гына укый башласаң да, бер утыруга ук азагына җитмичә туктый алмыйсың. Гомумән, Н.Гыйматдинованың иҗат манерасы (әсәрләрнең фабуласы, композициясе, пафосы) бик үзенчәлекле: ул бүген реаль тормышны тасвирлый, ләкин башка күп кенә әдипләр кебек, аны, фотографлар шикелле,

ничек бар, шулай “челт” иттереп кенә төшереп алмый, тормыш чынбарлыгын күңел күзе аша, акыл аша үткәреп күрсәтә”[3, б.77].

Үз алдыбызга Н.Гыйматдинова әсәрләрендәге пейзаж тудыруда катнашучы тел-сурәтләү чараларын күрсәтү максатын куйганлыктан, әсәрләрне бик җентекләп, һәр сүзен бөртекләп укып чыктык һәм тикшереп анализлау түбәндәге нәтиҗәләрне күрсәтте.

Нәбирә Гыйматдинованың геройлары – табигать баласы, һәм ансыз яши алмыйлар. “Болан” повестендагы Сузгын карчык белән Акчәч, “Сәвилә”дәге Маһруй әби белән Сәвия, “Ут күбәләге”ндәге Мөнәвәрә дә шундыйлардан. Аның әсәрләренең исеме дә табигать белән бәйле. Бу очраклы түгел. Язучының барлык әсәрләре аша үткән фикере – бары тик табигать белән берлектә генә кешенең эчке дөньясын тулы күрсәтеп була. Кешенең табигать кочагында күрсәтелүе геройның кичерешләрен тирәнрәк ачарга булыша. Аның геройлары табигатьтә яшәп кенә калмыйлар, алар үз хисләренең нечкәлеге, теләкләренең зурлыгы аркасында хәтта табигатьнең бер өлешенә әйләнеп китә ала. Язучы геройларының кешеләргә мөнәсәбәте дә табигать аша туа.

Әдип тудырган әсәрләрдә вакыйгалар, күренешләр, төрле хәлләр шундый итеп сурәтләнә, реаль тормышта болай була алмаганлыгын аңлап торасың, ләкин барысына да ышанасың. Мондый әсәрләр күбрәк дулкынландыра, хыялны уята, шулай булырга тиеш, дип ышанып кабул итәсең. Язучының әсәрләрендә урынлы кулланган сурәтләү чаралары ярдәмендә тулаем сәнгатьлелек, аһәңлелек арта. Автор геройлардагы эчке кичерешләрне табигать күренешләре белән бергә үрелдереп бирә. Табигать күренешләре еш кына сурәтләнгән вакыйгаларда актив катнашучы булып китәләр.

Н.Гыйматдинованың бу әсәрләрендә кешене табигатьтән аерып булмый. Сәвилә дә, Акчәч тә, Мөнәвәрә дә – табигать балалары. Табигать аларның йөрәге дә, җаны да, рухы да, тормышы да, гомере дә. Табигатьне сөя, ярата белү кеше күңеленең байлыгы турында сөйли. Автор моңа һәркемнең дә сәләтле булмавының табигатьнең һәлакәтенә китерүен әйтергә тели. Авторның үзе дә төп геройлар кичергәнне кичерә, газаплана. Пейзажны бирүдә

кулланылган тел-сурәтләү чараларын табигатьнең фаҗигасен үзенең йөрәге аша кичергән кеше генә түбәндәге өзекләрдәгечә бирә аладыр дип уйлыйм мин. ”Тик Галиҗәнап үсемлек, нәселен күпме генә сакларга теләсә дә, кешеләр – нәкъ менә акыллы тапкыр кешеләр – басып алып аның илен үлемгә дучар итте. Кан коелмыйча гына җан коелды... Җансыз тугайлар, җансыз болыннар, әрәмә-су буйлары артты. Таптады, изде кеше, рәхимсез изде. Карчык исемен атап та төртеп  күрсәтә алмаган үлән-чәчәкләр күп иде, алар җир өстеннән эзсез югалган иде. ”Тагын да югалыр, – диде карчык, шомлы тавыш белән, – тагын да югалыр. Адәм туфрагы-ние белән йотадыр, адәм – аждаһадыр”.

Н.Гыйматдинованың гомуми күләме 294 битлек булган “Сәвилә”, “Ут күбәләге”, “Болан” повестьларында пейзаж тудыруда катнашучы күчерелмә мәгънә белән бәйләнешле стилистик алымнар (метафора, чагыштыру, сынландыру, эпитет), лексик чаралар (синоним, антоним, фразеологизмнар), кабатлаулар тикшерелде. Әлеге әсәрләрдә барлыгы 372 тел-сурәтләү чарасы пейзаж тудыруда катнашкан. Аерым алганда 21 метафора, 14  чагыштыру, 75 сынландыру, 59 эпитет, 50 синоним, 17 антоним, 83 фразеологизм, 53 кабатлау. Иң күп кулланылган тел сурәтләү чарасы – фразеологизмнар. Алар – 49%.  Иң аз кулланылган сурәтләү чаралары – чагыштырулар һәм антонимнар. Алар – 8%ны тәшкил итә.

Н.Гыйматдинованың бу әсәрләрендә кешене табигатьтән аерып булмый. Сәвилә дә, Акчәч тә, Мөнәвәрә дә – табигать балалары. Табигать аларның йөрәге дә, җаны да, рухы да, тормышы да, гомере дә. Табигатьне сөя, ярата белү кеше күңеленең байлыгы турында сөйли. Автор моңа һәркемнең дә сәләтле булмавының табигатьнең һәлакәтенә китерүен әйтергә тели. Авторның үзе дә төп геройлар кичергәнне кичерә, газаплана. Пейзажны бирүдә кулланылган тел-сурәтләү чараларын табигатьнең фаҗигасен үзенең йөрәге аша кичергән кеше генә түбәндәге өзекләрдәгечә бирә аладыр дип уйлыйм мин. *”Тик Галиҗәнап үсемлек, нәселен күпме генә сакларга теләсә дә, кешеләр – нәкъ менә акыллы тапкыр кешеләр – басып алып аның илен үлемгә дучар итте. Кан коелмыйча гына җан коелды... Җансыз тугайлар, җансыз болыннар,*

*әрәмә-су буйлары артты. Таптады, изде кеше, рәхимсез изде. Карчык исемен атап та төртеп  күрсәтә алмаган үлән-чәчәкләр күп иде, алар җир өстеннән <u>эзсез югалган</u> иде. ”Тагын да югалыр, – диде карчык, шомлы тавыш белән, – тагын да югалыр. Адәм туфрагы-ние белән йотадыр, адәм – аждаһадыр”* [2, б.37].

Н.Гыйматдинованың бу әсәрләре тел-сурәтләү чараларына бай. Урыны-урыны белән текстта фразеологик әйтелмәләрнең, башка тел-сурәтләү чараларының кулланылганы сизелми дә. Хәер, әгәр ул үзенең барлыгын сиздереп торса, әсәр җирлегендә табигый ятмаса, ягъни фикерне ачык, төгәл белдерүгә, сөйләмнең эмоциональ яктан яңгырашына ярдәм итмәс иде.

Тел-сурәтләү чаралары ярдәмендә язучы әсәр телен искиткеч матур, сурәтле итә. Укучы күз алдына вакыйгалар, табигать күренешләре җанланып, могҗизалы сурәт булып килеп басалар.

Кулланынлган әдәбият исемлеге:

1. Бәширова И.Б. Хәзерге татар әдәби теле. Семасиология: Татар лексикасында системалы бәйләнеш-мөнәсәбәтләр. – Казан: Алма-Лит, 2006. – 196 б.

2. Гыйматдинова Н.М. Повестьлар. Икенче китап. – Казан: Идел-Пресс, 2010. – Б.37.

3. Курбатов Х. Поэтик проза остасы// Мәгариф журналы. – 2002. –  №3. – Б.77.